| | |
|---|---|
| СОВЕТ БОЛЬШЕШИРДАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ШЫРДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | Олы Шырдан | **КАРАР** |
| «18» ноябере 2024 ел | авылы | №184 |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Олы Шырдан авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру Ел саен Олы Шырдан авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2024 елның 13 февралендәге 156 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук
адреслары: Олы Шырдан ав., Г. Тукай ур., 10 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Олы Шырдан ав., Киров ур., 6 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.Глава

**Олы Шырдан Башлыгы**
**авыл җирлеге, Совет Рәисе** **Р. Р. Кәримов**